**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2020 елның 3 февралендәге** **3-РС номерлы**

# КАРАР

**Лаеш район Советының 2011 елның 19 декабрендәге 117-РС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясен тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шәһәр төзелеше һәм инвестиция эшчәнлеген, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 10, 18 - 21 статьялары, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясы нигезендә Лаеш муниципаль берәмлеген икътисадый үстерү максатларында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Лаеш районы Советының 2011 елның 19 декабрендәге 117-ТРЗ номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертүне расларга.

2. Лаеш муниципаль районы башкарма комитетына (архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертүне күрсәтүне территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасы сайтында https://fgistp.economy.gov.ru. веб-адресы буенча урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Кама ягы» газетасында , http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми порталында һәм Интернет-телекоммуникация челтәренең Лаеш муниципаль районы сайтында:http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирләрдән файдалану, төзелеш, төзекләндерү һәм экологик иминлек мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

**Муниципаль район**
**Башлыгы урынбасары** **Т.П.Борһанова**